**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ**
**Старочелнинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**Әлки муниципаль районы**
**Иске Чаллы авыл Җирлеге**
**БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Адрес: 422876, РТ, с. Старые Челны, ул. Центральная, дом 20
тел: : 8 (84346) 79-4-53

Адресы: 422876, РТ, Иске Чаллы авылы, Үзәк ур. 20 йорт
факс: 8 (84346) 79-4-53

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — Иске Чаллы авылы — КАРАР

2025 елның 16 нчы мае — 19 №

**Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү Тәртибен раслау турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $174^3$ маддәсе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә гомуми таләпләр турында»гы карары нигезендә, Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге өчен салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен расларга.

2. Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә 1 сентябрьгә кадәр муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына хисап елы, хисап елына кадәрге ел өчен белешмәләр җибәрүне тәкъдим итәргә:
ташламалардан файдаланган түләүчеләр саны турында;
Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге бюджетының төшеп калган керемнәр суммалары турында;
Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең һәр салым чыгымы буенча.

3. ТР Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның «21» мае 9 № карары белән расланган «2020 елда ТР Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү тәртибен раслау турында»гы карары үз көчен югалткан дип танырга.

4.Бу карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы"нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырырга, Әлки муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземә калдырам.

Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе в.б. — Р.С.Мусин

Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авылҗирлеге
Башкарма комитетының
2025 елның «16» мае, 19№
карары белән расланды

Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлеге салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм салым чыгымнарын бәяләү
Тәртибе

## I. Гомуминигезләмәләр

1. ӘлегеТәртип Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең салым чыгымнары исемлеген формалаштыру һәм Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең салым чыгымнарын бәяләү кагыйдәләрен билгели (алга таба – Тәртип, муниципаль берәмлек).

2. Әлеге тәртиптә «Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 22 июнендәге 796 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясе субъектларының һәм муниципаль берәмлекләрнең салым чыгымнарын бәяләүгә карата гомуми таләпләр белән билгеләнгән терминнар һәм төшенчәләр (алга таба-Гомуми таләпләр) кулланыла.

3.Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын муниципаль программаларга кертү муниципаль программаларның максатларыннан, муниципаль программаларның структур элементларыннан һәм (яки) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисади сәясәте максатларыннан чыгып гамәлгә ашырыла.

4. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты:

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзи;

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләрен анализлый һәм гомумиләштерә.

## II. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеген төзү

5. Чираттагы финанс елына һәм план чорына муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлеге муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан төзелә һәм агымдагы елның 1 июненә кадәр раслана.

6. Муниципаль берәмлекнең расланган салым чыгымнары исемлеге, агымдагы елның 1 июленнән дә соңга калмыйча, муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштырыла.

7. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү максатларында федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе муниципаль берәмлекнең башкарма комитетына хисап финанс елы өчен һәм хисап елына кадәрге ел өчен муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының фискаль характеристикалары турында мәгълүмат тапшыра.

8. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләүне уздыру максатларында муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты ел саен, 1 августка кадәр, Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә салым чыгымнарына китерүче муниципаль норматив хокукый актларны күрсәтеп, түләүчеләр категорияләре турында мәгълүматны, шул исәптән хисап елында һәм хисап елы алдыннан гамәлдә булган мәгълүматны, шулай ук әлеге Тәртипкә кушымтада каралган башка мәгълүматны җибәрә.

9. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә кертелгән мәгълүматны үзгәртүне күздә тота торган норматив хокукый актлар кабул ителгән очракта, муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тиешле норматив хокукый акт үз көченә кергән көннән алып 10 эш көне эчендә муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары исемлегенә тиешле үзгәрешләр кертә.

III. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү тәртибе.

10. Салым чыгымнарын бәяләү муниципаль берәмлекнең башкарма комитеты тарафыннан башкарыла һәм ул түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары күләмнәрен бәяләү;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү.

11. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатка ярашлылыгын бәяләү;
- муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү.

12. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының максатка ярашлылык критерийлары:

муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының муниципаль программалар максатларына, муниципаль программаларның структур элементларына һәм (яки) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисади сәясәте максатларына туры килүе;

ташламалар алу хокукыннан файдаланган түләүчеләр саны һәм биш еллык чорда түләүчеләрнең гомуми саны нисбәтендә характерлана торган салым ташламаларына салым түләүчеләр тарафыннан ихтыяҗ булу.

Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары әлеге пунктта күрсәтелгән критерийларның берсенә генә булса да туры килмәгән очракта, муниципаль берәмлекнең башкарма комитетытүләүчеләр өчен ташламаларны саклау (төгәлләштерү, гамәлдән чыгару) турында тәкъдимнәр кертергә тиеш.

13. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеге критерие буларак муниципаль программа максатларына яки муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисади сәясәт максатларына ирешүнең кимендә бер күрсәткече (индикаторы) яки муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары йогынты ясаган башка күрсәткеч (индикатор) билгеләнә. Әлеге күрсәткеч (күрсәткечләр) хисап елы, хисап елы алдыннан, агымдагы финанс елы, чираттагы финанс елы һәм планлы период өчен билгеләнә.

Муниципаль программа максатларына ирешү күрсәткеченең (индикаторының) һәм (яисә) муниципаль программаларга карамаган муниципаль берәмлекнең социаль-икътисади сәясәте максатларының әһәмиятен үзгәртүгә түләүчеләр өчен каралган ташламаларның өлеше бәяләнергә тиеш, ул күрсәтелгән күрсәткечнең (индикаторның) күрсәткече белән ташламаларны исәпкә алмыйча күрсәтелгән күрсәткечнең (индикаторның) күрсәткече арасындагы аерма буларак исәпләнә.

14. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнары нәтиҗәлелеген бәяләү муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне үз эченә ала.

15. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарының бюджет нәтиҗәлелеген бәяләүне уздыру максатларында ташламалар бирү нәтиҗәлелеген муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисади сәясәт максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарын куллану нәтиҗәлелегенәчагыштырма анализ ясала.

16. Чагыштырма анализ муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең социаль-икътисадый сәясәте максатларына ирешүнең муниципаль программаларга карамаган альтернатив механизмнары кулланылган очракта муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнары күләмнәрен һәм бирелгән ташламалар күләмен чагыштыруны үз эченә ала (муниципаль берәмлекнең муниципаль программалары максатларына ирешү күрсәткеченең

(индикаторының) һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларына карамаган социаль-икътисади сәясәт максатларының үсешен муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларының салым чыгымнарының 1 сумына һәм, альтернатив механизмнар кулланылган очракта, шул ук күрсәткечкә (индикаторга) ирешү өчен муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарының 1 сумына исәплəп чыгару).

Муниципаль берәмлекнең муниципаль программасы максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең муниципаль программаларга карамаган социаль-икътисади сәясәте максатларына ирешүнең альтернатив механизмнарыбуларак, шул исәптән түбәндәгеләр исәпкә алынырга мөмкин:

а) ташламаларга хокуклы түләүчеләргә муниципаль берәмлек бюджеты акчалары исәбеннән субсидияләр яисә турыдан-туры финанс ярдәменең башка рәвешләре;

б) ташламаларга хокуклы түләүчеләрнең йөкләмәләре буенча муниципаль гарантияләр бирү;

в) ташламаларга хокуклы түләүчеләр эшчәнлеге өлкәсендә контроль-күзәтчелек функцияләрен норматив җайга салуны һәм (яисә) гамәлгә ашыру тәртибен камилләштерү.

17. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү 1 октябрьгә кадәр гамәлгә ашырыла һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

- салым чыгымнарын бәяләүне уздыру өчен күрсәткечләр исемлеге буенча мәгълүмат;

-салым чыгымының максатчан характеристикаларына ирешүе (ирешмәве) турында, салым чыгымының муниципаль программа максатларына һәм (яисә) социаль-икътисади сәясәт юнәлешләренә (максатларына) ирешүгә керткән өлеше турында нәтиҗәләрне үз эченә алган язма аңлатмалар;

- аларга ирешүнең нәтиҗәлерәк альтернатив механизмнары булуы (булмавы) турындагы тәкъдимнәр;

- салым чыгымнарын саклап калу, төгәлләштерү (юкка чыгару), яңа салым чыгымнарын билгеләү буенча тәкъдимнәр.

18. Муниципаль берәмлекнең салым чыгымнарын бәяләү нәтиҗәләре муниципаль берәмлекнең бюджет һәм салым сәясәтенең төп юнәлешләрен формалаштырганда, шулай ук муниципаль программаларны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләгәндә исәпкә алына.

Әлки муниципаль районы
Иске Чаллы авыл җирлегенең
салым чыгымнары исемлеген
формалаштыру Тәртибенә
кушымта

Әлки муниципаль районы Иске Чаллы авыл җирлегенең
салым чыгымнарынбәяләүне уздыру өчен күрсәткечләр исемлеге

| Күрсәткечисеме | | Мәгълүмат (белешмәләр) чыганагы |
|---|---|---|
| I.Муниципаль берәмлекнең салым чыгымының норматив һәм максатчан характеристикалары. | | |
| 1. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, салымнар буенча азат итүләрне һәм башка өстенлекләрне билгели торган норматив хокукый акты. | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 2. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат итүләрне һәм башка өстенлекләрне бирү шартлары | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |

| | | |
|---|---|---|
| 3. | Салым ташламалары, азат итүләр һәм башка өстенлекләркаралган салым түләүчеләрнең максатчан категориясе | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 4. | Муниципаль берәмлекнең салым ташламаларын, салымнар буенча азат итүләрне һәм башка өстенлекләрне билгели торган норматив хокукый актлары нигезләмәләренең үз көченә керү датасы . | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 5. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламаларына, салымнар буенча азат ителүгә һәм башка өстенлекләргә хокукның гамәлдә булу датасы. | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 6. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән бирелгән салым ташламалары, азат итүләр һәм салымнар буенча башка өстенлекләр гамәлдә булу чоры. | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 7. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салымташламаларының, салымнар буенча азат ителүләрнең һәм башка өстенлекләрнең гамәлдә булуын туктату датасы. | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 8. | Салым ташламалары, салымнар буенча азат ителүләр һәм башка өстенлекләр исеме. | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 9. | Салым чыгымының максатчан категориясе (социаль ярдәм, стимуллаштыручы яисә техник ташлама) | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 10. | Салым түләүчеләргә муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актларында билгеләнгән салым ташламаларын, азат итүләрне һәм башка өстенлекләрне бирүнең максатлары. | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 11. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары белән билгеләнгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка өстенлекләр каралган салым төрләренең исемнәре. | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 12. | Салым ташламаларының, азат итүләрнең һәм башка өстенлекләрнең башка түләүчеләр белән чагыштырганда салым түләүчеләрнең аерым категорияләренә бирелгән өстенлекләрнең үзенчәлекләрен билгели торган төре | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 13. | Салым ташламалары, салымнар буенча азат итүләр һәм башка өстенлекләр бирелә торган салым ставкасы күләме. | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 14. | Салым ташламалары, салымнар буенча азат итүләр һәм башка өстенлекләр бирелүгә бәйле рәвештә муниципаль программаларның максатларына һәм (яисә) муниципаль берәмлекнең дәүләт программаларына карамаган социаль-икътисади сәясәт максатларына ирешү күрсәткече (Индикаторы) | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| II. Салым чыгымының фискаль характеристикалары | | |

| | | |
|---|---|---|
| 15. | Муниципаль берәмлекнең норматив хокукый актлары нигезендә хисап елы һәм хисап елына кадәрге ел өчен салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, азат итүләр һәм башка өстенлекләр күләме (мең сумнарда). | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
| 16. | Агымдагы финанс елына, чираттагы финанс елына һәм план чорына салым түләүчеләр өчен бирелгән салым ташламалары, азат ителүләр һәм башка преференцияләр күләмен бәяләү (мең сумнарда) | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |
| 17. | Муниципаль берәмлекнең хокукый актлары белән билгеләнгән салым ташламасыннан, азат ителүдән һәм башка өстенлектән файдаланган салым түләүчеләр саны (берәмлекләрдә). | Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе |
| 18. | Салым чыгымнарының нәтиҗәлелеген бәяләү нәтиҗәсе. | Муниципаль берәмлекнең Башкарма комитеты |